**СОВЕТ МАТЮШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТЮШИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

---

**2023 елның 14 декабре** **142 номер**

## КАРАР

**Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»2018 елның 12 ноябрендәге 154 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 04 июнендәге 96 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (беренче өлеш) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге территориясендә санитар һәм экологик торыш, чисталык һәм тәртип саклау өчен предприятиеләрне, оешмаларны, учреждениеләрне, вазыйфаи затларны һәм гражданнарны тикшереп торуны көчәйтү һәм аларның җаваплылыгын арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге Советы карар итте**:**

1. Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»2018 елның 12 ноябрендәге 154 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Матюшино
авыл җирлеге Советы рәисе** **Н.И.Миннуллина**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Матюшино  авыл җирлеге Советының
2023 елның 14 декабрендәге 142 номерлы
карарына кушымта

Лаеш муниципаль районы Матюшино  авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино  авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»2018 елның 12 ноябрендәге 154 номерлы карарына үзгәрешләр кертү

1. **1. 41.2, 85.3, 128.1, 144.7 пунктларына** «гамәлдәге законнар нигезендә» сүзләрен өстәргә;
2. **143 нче бүлекне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яшел утыртмалар хуҗаларына тәкъдим ителгән"